КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 август г.Казань № 996

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм капиталь ремонтлауга дәүләт ярдәме чаралары турында» 2022 ел, 13 июнь, 554 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм капиталь ремонтлауга дәүләт ярдәме чаралары турында» 2022 ел, 13 июнь, 554 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 4 август, 760 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

бишенче һәм сигезенче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Яшелчә саклагычлар, җиләк-җимеш саклагычлары һәм бәрәңге саклагычлар төзү (реконструкцияләү) эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе.»;

Әлеге карар белән расланган Ындыр табагы хуҗалыклары объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкару белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

6 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Сайлап алуда катнашучылар  гариза бирелгән датага кадәр 15 эш көненнән артмаган датага  түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

7 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтындагы Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«салым органының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын

раслый торган, заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән белешмә кәгазе (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир кишәрлеге урнашкан урын буенча муниципаль район яисә шәһәр округы башкарма комитеты тарафыннан бирелгән ындыр табаклары хуҗалыкларын төзүгә (реконструкцияләүгә) рөхсәт күчермәсен;»;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль районның яисә шәһәр округының башкарма комитеты тарафыннан хисап елыннан да иртәрәк булмаган вакытта бирелгән объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт күчермәсен;»;

унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«заявка биргән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларында ындыр табагы хуҗалыгы объектларына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;»;

егерме сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка биргән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларында ындыр табагы хуҗалыгы объектларына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.»;

10 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

14 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«W = P \times 0{,}3,»;$$

дүртенче һәм бишенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «объект» сүзен «объектлар» сүзенә алмаштырырга;

җиденче абзацта «объект» сүзен «объектлар» сүзенә алмаштырырга;

15 пунктта:

икенче абзацта «агымдагы финанс елның 31 декабренә» сүзләрен «заявка бирү датасына» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «агымдагы финанс елның 31 декабренә» сүзләрен «заявка бирү датасына» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Бирелгән субсидия, субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүмат дөрес булмау факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән шартлар бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапны тапшырмаган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракларда, Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе

алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрә кире кайтарылырга тиеш.

20 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Азык үзәкләрен төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда төзелгән стационар миксерлар белән тәэмин ителгән азык үзәкләре, азык туплау буенча һөнәри программа тәэмин ителеше, азык компонентын бирүнең системасы (җайланмасы) булу;»;

6 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Сайлап алуда катнашучылар гариза бирелгән датага кадәр 15 эш көненнән артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

7 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтындагы Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«салым органының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеналар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган, заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән белешмә кәгазе (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир кишәрлеге урнашкан урын буенча муниципаль район яисә шәһәр округы башкарма комитеты тарафыннан бирелгән азык үзәкләретөзүгә рөхсәт күчермәсен;»;

уналтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль районның яисә шәһәр округының башкарма комитеты тарафыннан хисап елыннан да иртәрәк булмаган вакытта бирелгән объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт күчермәсен;»;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка биргән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларында азык үзәкләренә төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;»;

10 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

14 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«W = P \times 0{,}3,»;$$

дүртенче һәм бишенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «азык үзәгенең» сүзләрен «азык үзәкләренең» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «азык үзәгенең» сүзләрен «азык үзәкләренең» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта:

беренче абзацта «агымдагы финанс елның 31 декабренә» сүзләрен «заявка бирү датасына» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Бирелгән субсидия, субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүмат дөрес булмау факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән шартлар бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапны тапшырмаган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракларда, Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

20 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Кимендә 200 баш куәтле сыер абзарларына капиталь ремонт эшләрен башкаруга һәм саву-сөт блоклары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

1 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

6 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Сайлап алуда катнашучылар  гариза бирелгән датага кадәр 15 эш көненнән артмаган датага  түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 процентттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры

булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

7 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтындагы Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«салым органының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган, заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән белешмә кәгазе (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);»;

тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җир кишәрлеге урнашкан урын буенча муниципаль район яисә шәһәр округы башкарма комитеты тарафыннан бирелгән сөт савып алу блоклары төзүгә рөхсәт күчермәсен;»;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«муниципаль районның яисә шәһәр округының башкарма комитеты тарафыннан хисап финанс елыннан да иртәрәк булмаган вакытта бирелгән объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт күчермәсен;»;

унсигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«заявка биргән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларында сөт савып алу блокларына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;»;

утызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка биргән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларында кимендә 200 баш куәтле сыер абзарларына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;»;

10 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

14 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«W = (P_1 \times 0,3) + (P_2 \times 0,3),»;$$

дүртенче, бишенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «сыер абзары» сүзләрен «сыер абзарлары» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче һәм сигезенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

тугызынчы абзацта «сөт савып алу блогы» сүзләрен «сөт савып алу блоклары» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «сыер абзары» сүзләрен «сыер абзарлары» сүзләенә алмаштырырга, «сөт савып алу блогы» сүзләрен «сөт савып алу блоклары» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта:

икенче абзацта «агымдагы финанс елның 31 декабренә» сүзләрен «заявка бирү датасына» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «агымдагы финанс елның 31 декабренә» сүзләрен «заявка бирү датасына» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. Субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәсенә ирешү турында, субсидия алу елыннан соң килүче елның 15 февраленә кадәр, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типлаштырылган килешү формасы буенча хисап тапшыра.»;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Бирелгән субсидия, субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүмат дөрес булмау факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән шартлар бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапны тапшырмаган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракларда, Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

20 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган 140 баштан 390 башка кадәр егәрлекле сыерлар абзарлары һәм 500 баштан һәм 5000 башка кадәр егәрлекле сарыкчылык фермаларын төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

6 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Сайлап алуда катнашучылар гариза бирелгән датага кадәр 15 эш көненнән артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы https:://subsidiya.tatar.ru яки https:://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада язылa торган заявка тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмә кәгазе;

капиталь төзелеш объектының проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе;

капиталь төзелеш объекты төзелешенең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе (аерым тора торган, катлар саны иң күбе ике булган, гомуми мәйданы иң күбе 1 500 кв.метр тәшкил иткән капиталь төзелеш объектлары өчен);

эшләр башкару сыйфатына һәм күләмнәренә төзелеш контролен гамәлдә ашыруны күздә тота торган шартнамә;

җыелма смета исәп-хисабы;

локаль смета исәп-хисаплар;

төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга подряд шартнамәләре;

төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма белән проект документациясенең башкарылган эшләренә оешма белән туры килүенә килештерелгән «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре;

«Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәтләре турында белешмә кәгазе» дигән КС-3 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре;

хисап һәм (яки) агымдагы финанс елында башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре;

хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларында 140 баштан 390 башка кадәр куәтле сыер абзарларына һәм (яисә) 500 баштан 5 000 башка кадәр куәтле сарык фермаларына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан заявка биргән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән өземтәләр.

Сервис автоматлаштырылган режимда ала торган документлар:

Юридик затларның бердәм дәүләт ресстрыннан яки Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән критерийларга һәм әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган өземтә;

сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе.

Сайлап алуда катнашучы заявкаларны кабул итү срогы чыкканга кадәр заявканы теләсә кайсы вакытта кире алырга, җитешсезлекләрен бетерергә һәм заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срок эчендә төзәтелгән документларның тулы пакетын кабат бирергә хокуклы. Шул ук вакытта документлар пакеты белән төзәтелгән заявка кабат кергән көнендә заявкалар керү чираты тәртибе буенча теркәлә.»;

8 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

10 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

14 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«W = (P_1 \times 0{,}3) + (P_2 \times 0{,}3),»;$$

дүртенче, бишенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «сыер абзары» сүзләрен «сыер абзарлары» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче һәм сигезенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

тугызынчы абзацта «сарык фермасы» сүзләрен «сарык фермасы» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «сыер абзары» сүзләрен «сыер абзарлары» сүзләренә алмаштырырга, «сарык фермасы» сүзләрен «сарык фермалары» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта:

беренче абзацта «агымдагы финанс елның 31 декабренә» сүзләрен «заявка бирү датасына» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Бирелгән субсидия, субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүмат дөрес булмау факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән шартлар бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапны тапшырмаган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракларда, Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

20 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Силос-сенаж траншеяларын төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

4 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 нчы календарь көннән иртәрәк була алмый);»;

6 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Сайлап алуда катнашучылар гариза бирелгән датага кадәр 15 эш көненнән артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы https:://subsidiya.tatar.ru яки https:://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада языла торган заявка тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмә кәгазе;

капиталь төзелеш объектының проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе;

капиталь төзелеш объекты төзелешенең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе (аерым тора торган, катлар саны иң күбе ике булган, гомуми мәйданы иң күбе 1 500 кв.метр тәшкил иткән капиталь төзелеш объектлары өчен);

җыелма смета исәп-хисабы;

локаль смета исәп-хисаплар;

төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга подряд шартнамәләре;

эшләр башкару сыйфатына һәм күләмнәренә төзелеш контролен гамәлдә ашыруны күздә тота торган шартнамә;

төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма белән проект документациясенең башкарылган эшләренә оешма белән туры килүенә килештерелгән «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре;

«Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәтләре турында белешмә кәгазе» дигән КС-3 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре;

хисап һәм (яки) агымдагы финанс елында башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре;

заявка биргән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларында силос-сенаж траншеяларына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Сервис автоматлаштырылган режимда ала торган документлар:

Юридик затларның бердәм дәүләт ресстрыннан яки Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 5 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән критерийларга һәм әлеге Тәртипнең 6 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларында билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслый торган өземтә;

сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе.

Сайлап алуда катнашучы заявкаларны кабул итү срогы чыкканга кадәр заявканы теләсә кайсы вакытта кире алырга, җитешсезлекләрен бетерергә һәм заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срок эчендә төзәтелгән документларның тулы пакетын кабат бирергә хокуклы. Шул ук вакытта документлар пакеты белән төзәтелгән заявка кабат кергән көнендә заявкалар керү чираты тәртибе буенча теркәлә.»;

8 пунктның икенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

10 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәләренең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);»;

14 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«W = P \times 0,3,»;$$

дүртенче һәм бишенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

алтынчы абзацта «силос-сенаж траншеясы» сүзләрен «силос-сенаж траншеялары» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «силос-сенаж траншеясы» сүзләрен «силос-сенаж траншеялары» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктта:

беренче абзацта «агымдагы финанс елның 31 декабренә» сүзләрен «заявка бирү датасына» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Бирелгән субсидия, субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүмат дөрес булмау факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән шартлар бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапны тапшырмаган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракларда, Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

20 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карарга Яшелчә саклагычлар, җиләк-җимеш саклагычлары һәм бәрәңге саклагычлар төзү (реконструкцияләү) эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен өстәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 13 июнь, 554 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 21 август, 996 нчы
карары редакциясендә)

Яшелчә саклагычлар, җиләк-җимеш саклагычлары һәм бәрәңге саклагычлар төзү (реконструкцияләү) эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләре (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда башкарылган яшелчә саклагычлар, җиләк-җимеш саклагычлары һәм бәрәңге саклагычлар төзү (реконструкцияләү) эшләренең үтәлешенә бәйле чыгымнар өлешен (җиһазлар сатып алуга һәм өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнарны тотып калып) каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - тиешенчә субсидияләр, сайлап алуда катнашучылар, саклагычлар).

2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

3. Субсидия алучылар Министрлык тарафыннан, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар җибәргән тәкъдимнәрне (заявкаларны) (алга таба – заявкалар) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 15 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 һәм 9 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) кул куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән тыелып калган (калганнар) дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.

5. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторында каралган икътисадый эшчәнлекнең бер яисә берничә төрен гамәлгә ашыру (ОК 029-2014 (КДЕС Ред. 2) – 01.1, 01.2, 10.3, 47.1, 47.2);

милкендә хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда төзелгән (реконструкцияләнгән) саклагычлар булу;

үзлегеннән җайга салына торган оешмага кертелгән саклагычлар төзегәндә (реконструкцияләгәндә) төзелеш контроле үткәрү һәм әлеге эшне башкаручы белгечләр Төзелеш өлкәсендәге белгечләрнең илкүләм реестрына кертелгән шарт белән;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым юнәлешләр буенча агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 30 июнь, 514 нче карары белән расланган Агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә һәм (яисә) модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнар өлешен каплауга, шулай ук федераль бюджеттан финанслана торган сөт продукциясенең аерым төрләрен мәҗбүри маркировкалауны кертү өчен маркировка җиһазлары сатып алуга һәм аларны сәнәгать эксплуатациясенә кертүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә субсидияләр бирү тәртибе нигезендә шундый ук максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алучы булып тормый.

6. Сайлап алуда катнашучы заявка бирелгән датага кадәр 15 эш көненнән дә артмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау;

сайлап алуда катнашучы юридик зат үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшмәкәр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында

катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш.

7. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, түләү реквизитлары һәм почта адресы, электрон почта адресы күрсәтелгән, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча тутырылган заявка;

заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә Федераль салым хезмәтенең рәсми сайтындагы Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

салым органының салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмавын раслый торган, заявка бирү датасына кадәр 15 эш көненнән артмаган датага бирелгән белешмә кәгазе (сайлап алуда катнашучы мондый документны тапшырмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бирелергә тиешле субсидия турында исәп-хисап белешмә кәгазе;

капиталь төзелеш объектының проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе күчермәсен;

капиталь төзелеш объекты төзелешенең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе күчермәсен (аерым тора торган, катлар саны иң күбе ике булган, гомуми мәйданы иң күбе 1 500 кв.метр тәшкил иткән капиталь төзелеш объектлары өчен);

«җир кишәрлеге урнашкан урын буенча муниципаль район яисә шәһәр округы башкарма комитеты тарафыннан бирелгән саклагычлар хуҗалыкларын төзүгә (реконструкцияләүгә) рөхсәт күчермәсен;

башкарылган эшләрнең сыйфатын һәм күләмен төзелеш контролен күздә тоткан шартнамәнең күчермәсен;

җыелма смета исәп-хисабы күчермәсен;

локаль смета исәп-хисаплар күчермәләрен;

төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга подряд шартнамәләре күчермәләрен;

төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма белән проект документациясенең башкарылган эшләренә оешма белән туры килүенә килештерелгән «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре күчермәләрен;

«Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәтләре турында белешмә кәгазе» дигән КС-3 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре күчермәләрен;

хисап һәм (яки) агымдагы финанс елында башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре күчермәләрен;

«муниципаль районның яисә шәһәр округының башкарма комитеты тарафыннан хисап елыннан да иртәрәк булмаган вакытта бирелгән саклагычны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт күчермәсен;

заявка биргән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларында саклагычларга төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

Тапшырылган документларның күчермәләре сайлап алуда катнашучы тарафыннан таныклана.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганга кадәр теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы. Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка кергән көнендә чират тәртибендә теркәүгә алына.

8. Министрлык:

сайлап алуны уздыру турында игъланда билгеләнгән сайлап алуны уздыру срогы дәвамында заявкалар кергән көнне аларны кабул итү датасын һәм вакытын күрсәтеп теркәп бара;

заявкалар кабул итү турындагы белдерүдә күрсәтелгән сайлап алуны үткәрү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган унбиш көн эчендә аларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча сайлап алу нәтиҗәләре турында реестр төзи һәм заявка керү чираты нигезендә сайлап алуда җиңүче билгеләү турында йә заявканы алудан баш тарту турында карар кабул итә;

сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерү датасын, вакытын һәм урынын;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп), шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләре;

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

9. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучыларның бу Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик зат урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитының сарыф итеп бетерелүе.

10. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән биш эш көне эчендә субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә килешү төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, күчерү тәртибе;

субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

субсидия алучы тарафыннан Министрлык билгеләгән өстәмә хисапларны бирү формасы һәм сроклары;

субсидияне кире кайтару тәртибе;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган, Министрлыкка моңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешә алмаганда килешүне өзү хакында шарт;

Министрлык, кирәк булганда, субсидия алучылар белән Татарст ан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

11. Әлеге Тәртипнең 10 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокукы булган зат имзасы белән килешү проектын Министрлыкка тапшырмаган очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

12. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә күрсәтелгән килешүләргә кул кую срогы чыккан көннән бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы белән рәсмиләштерелә торган субсидия алучыларга субсидия бирү турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

13. Субсидия кире кайтару өчен бирелә торган чыгымнар юнәлешләре - КС-2 номерлы форма буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән саклагычлар төзүгә (реконструкцияләүгә) бәйле төзелеш, монтаж һәм башка эш төрләренә чыгымнар (җиһазлар сатып алуга һәм өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнарны тотып калып).

14. Әлеге Тәртипнең 1 пункты (W) (сумнарда) нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = P \times 0,3,$$

монда:

P - хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда саклагычлар төзүгә (реконструкцияләүгә) бәйле төзелеш, монтаж һәм башка төр эшләр өчен түләүгә факттагы чыгымнар, алар КС-2 формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән (өстәлгән бәягә салымны һәм җиһазлар сатып алуны исәпкә алмыйча), сум.

Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме саклагычлар төзүгә (реконструкцияләүгә) смета бәясенең 30 процентыннан арта алмый, моңа җиһазлар сатып алуга һәм өстәмә кыйммәткә салым түләүгә чыгымнар керми.

15. Субсидия бирү нәтиҗәсе - заявка бирелгән датага торышы буенча эксплуатациягә кертелгән саклагычлар саны (берәмлек).

16. Субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәсенә ирешү турында, субсидия алу елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типлаштырылган килешү формасы буенча хисап тапшыра.

17. Бирелгән субсидия, субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүмат дөрес булмау факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән шартлар бозылган, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган бозулар булган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисапны тапшырмаган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешелмәгән очракларда, Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренә кире кайтарылырга тиеш.

18. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган егерме көн эчендә әлеге акчаны

Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрә.

19. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

20. Субсидия алучы тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучыларның тиешле вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

---